**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**28 февраль 2023 ел** **№ 76**

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге Советы
депутаты статусы турында
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү
хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советы Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советының 2022 елның 28 октябрендәге 59 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 3 статьясындагы 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Нигезләмәнең 18 статьясындагы 1 пунктының б пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында Песәй авыл җирлегенең "Норматив документлар" бүлегендә урнаштырырга: www.mendeleevsk.tatar.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылык, хокук тәртибе һәм Кеше хокуклары буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге Советы рәисе В.И.Мөхәммәтгалеев